КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 02 июнь г.Казань № 682

«Түбән Кама шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесен һәм «Түбән Кама район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесен «Түбән Кама шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә «Түбән Кама район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесен кушу рәвешендә яңадан оештыру турында

Татарстан Республикасы дәүләт ветеринария хезмәте структурасын камилләштерү, Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының һәм дәүләт мөлкәтен файдалануның нәтиҗәлелеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенең 423570, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Чистай урамы, 58А йорт адресы буенча урнашкан «Түбән Кама район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба - Район ветеринария берләшмәсе) һәм 423577, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре, Спорт урамы, 12в йорт адресы буенча урнашкан «Түбән Кама шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесен (алга таба - Шәһәр ветеринария берләшмәсе) Район ветеринария берләшмәсен Шәһәр ветеринария берләшмәсенә кушу рәвешендә, әлеге пунктта күрсәтелгән үзгәртеп оештырыла торган учреждениеләр эшчәнлегенең төп максатларын Шәһәр ветеринария берләшмәсендә саклап калып, үзгәртеп оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Үзгәртеп оештыру процессы тәмамланганнан соң Шәһәр ветеринария берләшмәсе исемен «Түбән Кама район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә үзгәртергә.

3. Шәһәр ветеринария берләшмәсен гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башкара дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә:

эш көннәрендә исәпләнә торган 90 көн эчендә бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле булган, законнарда каралган чараларны үткәрүне тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Район ветеринария берләшмәсенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә;

Район ветеринария берләшмәсе эшчәнлеге туктатылу турындагы язу Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән датадан Шәһәр ветеринария берләшмәсе уставына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыруга бәйле чаралар аркасында эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

бу карарның 1 пунктында күрсәтелгән учреждениеләрне үзгәртеп оештыру чараларын үткәрү чыгымнарын тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе» ведомствосы буенча каралган акча чикләрендә финанслауны тәэмин итәргә;

5. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, бу карарның 4 пунктындагы дүртенче абзацында күрсәтелгән мөлкәт исемлеген алганнан соң, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Район ветеринария берләшмәсенә элегрәк беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Шәһәр ветеринария берләшмәсенә тапшыруны тәэмин итәргә.

6. Шәһәр ветеринария берләшмәсе дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе» ведомствосы буенча каралган акча чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә әлеге карарның 4 пунктында каралган чаралар үтәлгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга Татарстан Республикасы дәүләт

учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2022 ел, 22 сентябрь, 1031 нче карарына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәр кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин